| СОВЕТ<br>Девятернинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Девәтернә авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2024 Девәтернә авылы № 50-1

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елның 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Девәтернә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләүгә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге зурлыкта билгеләргә:

1) 0,1 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнары;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалар;

2) 0,2 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

квартиралар, квартираларның өлешләре, бүлмәләр;

3) 0,3 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;

4) 1,2 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

-Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы билгели торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар;

5) 2 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салына торган объектлар;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салына торган объектлар;

6) 2,5 процент түбәндә санап үтелгәннәргә карата:

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салына торган объектлар;

7) салым салына торган башка объектларга карата 0,5 процент.

3. Девәтернә авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын таныргa:

- «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы;

- 12.05.2015 елның 40-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 16.10.2015 елның 3-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 29.12.2018 елның 48-3 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 07.02.2020 елның 57-2 «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 07.09.2022 елның 21-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 елның 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында".

4. Әлеге карар аны игълан иткән көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасы 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булуын билгеләргә.

6. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасының гамәлдә булуын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. Ганиев

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Девятерчинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002645
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ